**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» февраль, 2023 ел № 123

«Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Питрәч муниципаль районы җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) аттестация тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 06 маендагы 721 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.«Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Питрәч муниципаль районы җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) аттестация тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы 1 абзацында «югары вәкиллекле, закон чыгару органы» сүзләрен «вәкиллекле һәм бердәнбер закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырырга;

- Нигезләмә тексты буенча «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

2. «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Питрәч муниципаль районы җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 октябрендәге 1550 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 2113 номерлы карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда:

http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Мәгариф бүлеге» МБУ башлыгы М.А. Харитоновка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин